Татар халкы гореф-гадәтләргә һәм йолаларга бик тә бай. Онытыла барганнары да бvгенге кондә янадан кайта башлады. Кайберләрен мәчет кайтара. Мәчет - ул Аллаһның бер Үзенә гыйбадәт кыла торган жире генә тvгел, ул - мәгрифәт нуры чәчә торган урын да. Язмабыз мәчет һәм анын эше турында. Нижний Новгород олкәсе Первомайск шәһәренә (элекке Ташино) кvрше булган Мордовиянен Ельники, Зубово-Поляна, Темниково, Краснослабодск һәм башка районнары татарлары анда кvпләп яши. Шул исәптән Первомайск шәһәре имамы Марат Кәмил улы Шехмаметьев та. Анын белән аралашканда мәчет турында сораштым. Ничек эшләп китvен һәм дин юлына басуын ул болай анлатты:

- Мәчетебез меценат Ариф Кәрим улы Мещеров ярдәме белән 2007нче елны тозелә башлады. Ариф Кәрим улы тумышы белән Нижний Новгород олкәсе Первомайск районы Верзаляй (Акчеевские Выселки) авылыннан. 2017нче елны мәчетебез «Аль-Кәрим» исеме белән эшли башлады. Мәчет ачылганчы биредә дога кылу йорты гына эшләп килде; анда Кәмил хәзрәт 80 яшенә кадәр халыкка традицион ислам кануннарын, татар халкы гореф-гадәтләрен һәм йолаларын кире кайтара башлады.

Бvген мин мәчетебездә дини кануннар кушкан вазыйфалар белән бергә, торле яшьтәге кешеләргә дини сабак-лар бирәм, дини бәйрәмнәребезне олылап vткәрәбез, халыкка дин кануннары турында хотбәләр сойлим, бигрәк мәктәпләрдә балаларга белемле булунын дәрәжәсен анлатырга тырышам, Ботендонья террорына каршы тору турында сойләшvләр vткәрәм. Мәчеттә экскурсияләрне vткәрергәндә психолог булган Галия

Рәхим кызы Кутуева белән мәдрәсә тәмамлаган Шамиль Кадим улы Садретдинов татар халкынын милли традицияләре турында да сойлиләр. Торле-торле акцияләрдә, Корбан гае тендә белән Рамазан айларында хәйриячеләребез-меценатларыбыз катнаша, мәсәлән, сонгыларынын берсендә АО «Трансплевматика» заводы, Ташино шәһәре халкы һәм Соләйман Керимов катнашты, - ди аралашканда Марат Кәмил улы Шехмаметьев.

Ә хәзер хәзрәт турында берничә сvз. Марат Кәмил улы Шехмаметьев тумышы белән Ельник районы Акчеево-Кvгеш авылыннан. Әтисе Кәмил Усман улы гомере буе Акчеевонын «50 лет СССР» колхозында тырышып тракксторчы булып хезмәт иткән, ә әнисе - Алия Шакир кызы «Сельхозтехника»да, аннары колхозда иген игvче, сыер савучы һәм башка хезмәткәрләрне, повар буларак, тәмле ашлар белән сыйлаган. Ә Кәмил улы Марат туган авылы мәктәбен тәмамлагач, авылларынын хормәтле имамы Кәрим хәзрәт Шехмаметьев (бакыйлыкка кvчте) юллавы буенча, Горький (Нижний Новгород) шәһәрендәге торек мәдрәсәсен тәмамлый. Әмма тиз генә дини хезмәткәр булмый ул. Башта, Ташинга кvчеп, заводта 9 ел токарь буларак хезмәт итә. Ташино имамы Кәмил хазрәт бакыйлыкка кvчкәч, халык Маратны хәзрәт вазыйфасын vтәргә сорала. Ул: «Халыкнын сvзен аяк астына салып таптарга ярамый. Дин юлына басарга Аллаһы Тәгалә насыйп итте. Әби-бабайлар дин юлында булды, минем кvнелемә дә хормәтле Кәрим хәзрәтебез дин орлыгы салып калдырды, мәдрәсәдә белем дә алдым».
Шулай, Первомайск-Ташино шәһәре «Аль-Кәрим» мәчете имамы Марат Кәмил улы Шехмаметьев, дин вазыйфалары белән бергә, шәһәр коммуналь хужалыкларнын берсендә мастер булып та эшли. Гаилә башы бит ул. Бvген Марат хәзрәтнен оендә татар халык гореф-гадәтләрен һәм йолаларын хормәтләп тыныч, матур тормыш итәләр. Оч кызлары аларны шатландырып vсә.

Наилә НАСЫРОВА